татарском языке синтезатор должен выявить принадлежность каждого слова тому или другому языку. А для того, чтобы сделать это, синтезатор должен уметь проводить морфологический анализ слова. Но осуществлять морфологический анализ слова невозможно без знания принадлежности слова определенному языку. Таким образом, синтезатор наталкивается на порочный круг.

Как известно, Фердинанд де Соссюр сравнивал язык с шахматами. Внесение в шахматы новой фигуры или изменение правил ее перемещения на шахматной доске изменяет всю игру. Точно так же внесение каких-либо новшеств (добавление фонемы или изменение сложившихся контекстных ограничений фонемы) в фонетическую систему языка, если и не приведет к образованию нового языка, но к определенным разрушениям ассоциативных связей между знаками и значениями, а также между значениями и понятиями приведет непременно [6].

Любой язык сформировался за многие тысячелетия, вобрал в себя опыт и знания многих поколений. Задача каждого нового поколения не экспериментировать (не создавать какие-то нормы), а беречь и обогащать язык в согласии с положениями известного уругвайского лингвиста Косериу «...норма соответствует не тому, что «можно сказать», а тому, что уже «сказано» и что по традиции «говорится» в рассматриваемом обществе» [7].

**Литература**

1. Бодуэн де Куртенэ, И.А. Язык и языки. Избранные труды по общему языкознанию. Т.2. / И.А. Бодуэн де Куртенэ. – М.: Наука, 1963. – 389 с.
2. Бодуэн де Куртенэ, И.А. Язык и языки. Избранные труды по общему языкознанию. Т.1. / И.А. Бодуэн де Куртенэ. – М.: Наука, 1963. – 382 с.
3. Богородицкий, В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками / В.А. Богородицкий. – Казань: Татгосиздат, 1953. – 220 с.
4. Шараф, Г. Палатограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими / Г. Шараф // Вестник научного общества татароведения. – Казань: Татгосиздат, 1927, № 7. – С.65-103.
5. Пешковский, А.М. Русский синтаксис в научном освещении / А.М. Пешковский. М.: Государственное учебно-педагогическое издательство Министерства просвещения РСФСР, 1956. – 511 с.
6. Косериу, Э. Синхрония, диахрония и история / Э. Косериу // Новое в лингвистике. Вып. 3. – М.: Издатинлит, 1963. – С. 143-346.

***Ибраһимова Альмира Хәлиловна***
Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА КУШМА ҖӨМЛӘНЕ ӨЙРӘТКӘНДӘ, СӘЛАМӘТЛЕК ТЕХНОЛОГИЯСЕН ФАЙДАЛАНУ

*Школа играет огромную роль в формировании здоровья учащихся. Школьники большую часть своей жизни проводят в школе. Здоровье – основа*

*развития личности. Статья посвящается использованию технологий здоровья на уроках татарского языка в общеобразовательных организациях.*

**Ключевые слова**: *здоровье, школьники, технологии, компьютер, личность.*

*The school plays an important role in shaping the health of pupils. Pupils most of their life lives at school. Health - the basis of human development. The article is dedicated to the use of health technology on the lessons of the Tatar language in educational institutions.*

**Key words***: health, pupils, technologies, computer, personality.*

Югары технологияләр, берсеннән-берсе көчле компьютерлар кулланыла торган заманда яшибез. Ләкин статистика мәгълүматлары буенча, сәламәт кешеләр саны көннән-көн кими бара.

Сәламәтлек дигәндә, беренче чиратта, кешенең физик саулыгы күз алдына килә. Бу юнәлештә эш алып барсак та, физик сәламәтлекне күбрәк медицина учреждениеләре кайгырта. Ә педагоглар буларак, без кеше сәламәтлегенең психик һәм социаль ягына күбрәк басым ясарга тиеш.

Укучыларның сәламәтлеген формалаштыруда мәктәп зур роль уйный, чөнки укучы үз тормышының биштән бер өлешен мәктәптә үткәрә. Белгечләр укучыларның сәламәтлеге, күбесенчә, укыту процессының үтәлү шартларына бәйле дигән нәтиҗәгә килә.

Хәзерге көндә укыту процессын укучы кызыксынырлык итеп үткәрү өчен, һәр укытучы яңа алымнар, яңа технологияләргә мөрәҗәгать итә. Әмма иң мөһиме: белем һәм тәрбия бирүдә укучыларның сәламәтлегенә зыян килерлек булмаска тиеш. Безнең бурычыбыз: һәр укучы өчен комфорт шартлар тудыру, һәр баланың индивидуальлеген искә алып, үсеп килүче яшь буын өчен үз-үзенә, үз көченә ышаныч тудыру, шәхес буларак үсәргә, ачылырга ярдәм итү.

Һәр гомуми белем бирү оешмалары, укучыларга белем һәм тәрбия бирү белән беррәттән, аларның сәламәтлеген кайгырту буенча нәтиҗәле эш алып бара. Спорт секцияләре, балаларның дөрес һәм режимлы туклануын тәэмин итү, кабинетларда чисталык һәм һава режимын төгәл үтәү, дәресләрдә уңай психологик атмосфера тудыру, сәламәтлек сәгатьләре үткәрү һ.б. – шуның кайбер элементлары.

Дәресләрдә сәламәтлек технологияләрен куллану да шушы эшнең бер өлеше. Мондый дәресләр үзенең формасы белән дә, структурасы белән дә, эш алымнары белән дә аерылып тора. Татар теле дәресләрендә укучыларның активлыгын максималь дәрәҗәгә җиткерү өчен, энергизаторлар, акыл штурмы, төркемле дискуссия, рольле уеннар, мини-лекция, кооператив белем бирү төркемнәрендә эшләү, төрле типтагы ял минутлары, күзләргә, кулларга, гәүдәгә гимнастика элементлары, музыка тыңлап ял итү кебек эш алымнары кулланыла. Шулай ук мәктәптә валеологик тәрбия бирүгә дә зур

урын бирелә. 8 нче сыйныф укучыларына иярчен сәбәп җөмләне аңлатканнан соң, белемнәрне ныгытыр өчен, интерактив тактада җөмләләр тәкъдим ителә (1. Шуны истә тотыгыз: сәламәт иң зур байлык. 2. Теләге бар кеше үз сәламәтлеген ныгытыр. 3. Вакытыгызны дөрес бүлергә өйрәнегез, чөнки сәламәтлек өчен эш һәм ялны бүлә белү дә бик кирәк. 4. Кыш җиткәч, чаңгыда һәм тимераякта шуу да бик файдалы). Укучылар шулар арасыннан иярчен сәбәп җөмләле кушма җөмләне табарга тиешләр. Ләкин ахырдан укытучы һәр җөмләнең мәгънәсенә төшенергә ярдәм итә торган, сәламәт яшәү теләге уятырлык сораулар бирергә тиеш, ягъни укучылар арасында фикер алышу оештырыла. Дәрестә спорт белән шөгыльләнүчеләрнең укудагы, спорттагы казанышларын мисал итеп китерү һәм аларның сәламәт булуын ассызыклау да уңай нәтиҗәләр бирә. Төрле милләт кешеләренең үз сәламәтлекләрен ничек кайгыртканнарын чагылдыра торган әсәрләрдән өзекләргә грамматик яктан анализ ясатып, соңыннан шул хакта дискуссия оештыру да дәресне җанландырып җибәрә, балаларда кызыксыну уята. Дәрес вакытында яисә дәрестән тыш чаралар үткәргәндә, теге яки бу тема белән бәйләп, озын гомер кичергән кешеләр белән дә таныштыру киңәш ителә.

Дәрес ахырында укучылар төркемнәргә бүленеп, аналитик һәм синтетик иярчен сәбәп җөмләләрне кулланып, «Сәламәтлек – зур байлык» дигән инша язып бирәләр.

9-11 сыйныфларда тренинглар куллану да уңышлы. Дәресләр тренинглар рәвешендә үткәрелә һәм монда түбәндәге методлардан файдалану күздә тотыла:

1. Төркем белән эшләү.
2. Бәхәс-дискуссияләр.
3. Әңгәмәләр.
4. Лекцияләр.
5. Сәхнәләштерү.
6. Түгәрәк өстәлләр.
7. Рольле уеннар [Харисов, 2002: 35].

Бу методлар татар әдәбияты белән предметара бәйләнешләрдә чагылыш таба. Укучылар үзләре өйрәнгән әсәрләрдән билгеле бер тема белән бәйле җөмләләр тупларга, яисә синтетик һәм аналитик җөмләләрне файдаланып, бәхәс-дискуссияләр, рольле уеннар һ.б. уздырырга тиешләр.

Сәламәтлек – шәхес үсешенең нигезе. Балалар – безнең киләчәгебез, терәгебез. Психик, рухи сәламәт шәхес тәрбияләү – безнең изге бурычыбыз.

**Әдәбият**

1. Харисов, Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр / Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова // Мәгариф. – 2002. – №1. – Б. 35-36.